**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«28» март 2026 ел № 6/2

**Физик затлар мөлкәтенә салым турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль берәмлеге «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Физик затлар мөлкәтенә салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә түләүгә мәҗбүри салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Салым ставкаларын күләмен билгеләргә:

1) 0,1 процент түбәндәгеләргә карата:

- мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясы 7 пункты нигезендә билгеләнгән исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясы 10 пункты икенче абзацында каралган салым салу объектында, салым түләүче сайлаган бер гаражга ки машина урынына карата;
- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык төзелмәләре яки корылмалары;

2) 0,2 процент түбәндәгеләргә карата:

- фатирлар, фатирларның өлешләре;
- бүлмәләр;

3) 0,3 процент түбәндәгеләргә карата:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;
- төзелеп бетмәгән объектлар, мондый объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;
- составына ким дигәндә бер торак бина (торак йорт) кергән бердәм күчемсез милек комплекслары;

4) 2 процент түбәндәгеләргә карата:

- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;
- Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы 7 пункты нигезендә билгеләнгән исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;
- Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы 10 пункты нигезендә каралган салым салу объектлары;

6) 1,2 процент 2025-2027 еллар көчеш чорына гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан алып 2000 квадрат метрга кадәр булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга һәм Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата;

7) 0,5 процент башка салым салу объектларына карата.

3. Күпфатирлы бер катлы торак йорттагы ике фатирдан торган фатирга милек хокукына ия физик затларга исәпләнгән салым суммасын әлеге фатирның гомуми мәйданы утыз квадрат метрының кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Фатир уртак милектә булган очракта, ташлама суммасы уртак милектә катнашучы һәркем өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан арта алмый.

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» РФ Президентының 21.09.2022 ел, № 647 Указы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарын физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә, 2023 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Салым ташламасы түбәндәге салым салу объектларына карата бирелә: фатирга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә, торак йортка, торак йорт өлешләренә. Салым ташламасы салым түләүче милкендә булган һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

4. Әлеге карар мәгълүмат стендларында һәм районның рәсми сайтында рәсми игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

5. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 23 сентябрендәге 14/5 номерлы карарының (26.09.2018 ел № 6/7, 13.11.2023 ел № 32/2, 01.10.2024 ел № 46/1 карарлар үзгәрешләре белән) гамәлдә булуын үз көчен югалткан дип танырга.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе — Р.Х. Сафина